**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

29.12.2021

№ 347

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2014 елның 13 декабрендәге 707 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 30 июлендәге 439 номерлы, 2016 елның 5 апрелендәге 221 номерлы, 2017 елның 9 гыйнварындагы 2 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге 342 номерлы, 2017 елның 16 декабрендәге 731 номерлы, 2018 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы, 2020 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы һәм 2020 елның 30 декабрендәге 398 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Эш төркеме составыннан А.В. Михайловны чыгарырга;

Эш төркеме составына Варфоломеева Елена Евгеньевнаны – Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасының баш суд приставы урынбасарын (килешү буенча) кертергә;

Эш төркеме әгъзасы О.В. Пелевинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары».

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**